# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ

## КАРАР №44

III чакырылыш XXVII утырыш Урыссу ш.т.б. 2019 елның “27” ноябре

*Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча*
*Татарстан Республикасы Президенты Идарәсенең*
*2016-2017 елларда Ютазы Советы депутаты*
*С. Р. Төхбәтуллинның керемнәр,чыгымнар, милек*
*һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында*
*бирелгән мәгълүматларының дөреслеген һәм тулылыгын*
*тикшерү нәтиҗәләрен карау турында*

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсенең 2019 елның 10 июлендәге 10-6232 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы район Советы

## КАРАР БИРӘ:

1. Ютазы муниципаль районы Советы депутаты Төхбәтуллин Сәгадәтулла Рәхмәтулла улы 2016-2017, 2018 елларда үз керемнәре, хатынының керемнәре турында дөрес һәм тулы булмаган мәгълүмат бирүен танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Советы депутаты С.Р. Төхбәтуллинга керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында дөрес һәм тулы мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә һәм коррупциягә каршы тору өлкәсендә законнар таләпләрен, чикләүләрен һәм тыюларын үтәмәүгә юл куймаска.

3. 2020 елның гыйнварында коррупциягә каршы тору өлкәсендә законнар таләпләрен, чикләүләрен һәм тыюларны үтәмәүгә юл куймау максатыннан, муниципаль хезмәткәрләр һәм депутатлар белән керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны дөрес тутыру буенча семинар оештырырга.

*Ютазы муниципаль районы башлыгы урынбасары –*
*Ютазы район Советы рәисе* *З.М. Әгълиева*